# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2025 елның 2 декабрендәге                                                  6 номерлы

Кукмара муниципаль районы Лубян авыл җирлегенең Чулыгино Авылы торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районының Лубян авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Лубян авыл җирлегенең Чулыгино авылын хәл иттеләр:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Лубян авыл җирлеге Чулыгино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләрдән һәм ялгыз аналардан тыш, 2026 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертергә; Бөек Ватан сугышы ветераннарын һәм балачактан инвалидларны; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срочная хәрби хезмәткә чакырылган затларны; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затларны һәм аларның гаилә әгъзаларын; Россия Федерациясе Кораллы көчләренә хезмәт итү контрактына кул куйган затларны һәм аларның гаилә әгъзаларын.
2. 2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Чулыгино авылында урам-юл челтәрен карап тоту, ком һәм вак таш сатып алу, ташу, салу, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр, трактор җиһазлары, махсус техника сатып алу, хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү, проект-смета документлары, технадзорны гамәлгә ашыру, юлларны карап тоту буенча башка төр эшләр);

- урамнарны яктырту җайланмасы (урамнарны яктыртуны карап тоту, яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка төр эшләр);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Чулыгино авылы территориясен төзекләндерү, проект-смета документациясе, эшләр өчен түләү)

3. Гражданнар җыены нәтиҗәсен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында , мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга:

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче башлык
Лубян авыл җирлеге — Г. Ф. Тежикова